СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

______________ с. Нижний Услон ______________

50-197

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 26.06.2013 ел, № 27-145 карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең әлеге проектны гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында,

Югары Ослан муниципаль районы
Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегенең № 1 нче кушымтасы нигезендә Түбән Ослан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы карары проектын кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының 2 нче кушымта нигезендә Югары Ослан муниципаль районы

Түбән Ослан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе ;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018 елның 12 октябрендә 10 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, Түбән Ослан авылы, Завод урамы, 1а йорт адресы буенча уздырырга.

4. Башкарма комитетка Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. 2018 елның 11 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А. З. Шәйдуллин